БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 01 » сентябрь 2021 ел № 271

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен булдыру турында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон,«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 21 пункты, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары,«Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» 2020 елның 20 февралендәге 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 27 гыйнварындагы ПУ-27 номерлы Указы, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләрен) булдыру турында» 2010 елның 15 гыйнварындагы 6 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында Гражданнар оборонасы чараларын һәрьяклы тәэмин итүне оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Расларга:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү турында нигезләмәне (1 нче кушымта).

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында коткару хезмәтләрен формалаштыру һәм аларның эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен (2 нче кушымта).

2. Авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару өчен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының коткару хезмәтләрен

төзергә һәм аларның структурасын расларга (3 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының коткару хезмәтләре җитәкчеләренә Карар рәсми басылып чыкканнан соң 2 ай эчендә хезмәтне оештыру-планлаштыру документларын эшләргә, килештерергә һәм билгеләнгән тәртиптә расларга.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов